ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 20 февралендә
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 2; 2010, № 1 – 2; 2011, № 5; 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 өлешнең алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«КС – стаж коэффициенты, ул муниципаль вазыйфаларны биш елдан җиде елга кадәр йә җирле үзидарә органы вәкаләтләрен тулы бер срок, әмма кимендә өч ел биләгәндә 0,45кә тиң; муниципаль вазыйфаларны кимендә җиде ел биләгәндә һәм муниципаль һәм (яисә) дәүләт вазыйфаларын биләү срогы (стажы), дәүләт һәм (яисә) муниципаль хезмәт стажы гомумән алганда кимендә унике ел булганда йә муниципаль вазыйфаларны кимендә ун ел биләгәндә 0,65кә тиң; муниципаль вазыйфаларны ун елдан артыграк биләгәндә һәм муниципаль һәм (яисә) дәүләт вазыйфаларын биләү срогы (стажы), дәүләт һәм (яисә) муниципаль хезмәт стажы гомумән алганда кимендә унбиш ел булганда йә муниципаль вазыйфаларны җирле үзидарә органының тулы ике срок вәкаләтләре дәвамында, әмма кимендә сигез ел биләгәндә һәм муниципаль һәм (яисә) дәүләт вазыйфаларын биләү срогы (стажы), дәүләт һәм (яисә) муниципаль хезмәт стажы гомумән алганда кимендә унбиш ел булганда 0,7гә тиң.»;

2) 5 өлешнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) муниципаль вазыйфаларны ун елдан артыграк биләгән һәм муниципаль һәм (яисә) дәүләт вазыйфаларын биләү срогы (стажы), дәүләт һәм (яисә) муниципаль хезмәт стажы гомумән алганда кимендә унбиш ел булган йә муниципаль вазыйфаларны җирле үзидарә органының тулы ике срок вәкаләтләре дәвамында, әмма кимендә сигез ел биләгән һәм муниципаль һәм (яисә) дәүләт вазыйфаларын биләү срогы (стажы), дәүләт һәм (яисә) муниципаль хезмәт стажы гомумән алганда кимендә унбиш ел булган затларга карата – дәүләт вазыйфаларын кимендә унбиш ел биләгән йә күрсәтелгән вазыйфаларны өч елдан артыграк биләгән һәм дәүләт хезмәте стажы гомумән алганда кимендә унбиш ел булган Татарстан Республикасы министрының дәүләт пенсиясенә өстәмә күләме буенча.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2020 ел, 13 март
№ 9-ТРЗ